| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |

«28» декабрь, 2023 ел Алабуга шәһәре № 324

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Предприятиеләргә, оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга муниципаль өстенлекләр (преференцияләр) бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 22 декабрендәге 33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 июлендәге 85-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2010 елның 22 декабрендәге 33 номерлы карары белән расланган, предприятиеләргә, оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга муниципаль өстенлекләр (преференцияләр) бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш), биналарны, төзелешләрне, корылмаларны, торак булмаган урыннарны, җиһазларны, механизмнарны, җайланмаларны, транспорт чараларын, инвентарьны, инструментларны, түләүле нигездә, түләүсез нигездә яисә ташламалы шартларда биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру рәвешендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджетның икътисади үсеше, салымнар, тариф сәясәте, эшмәкәрлеккә һәм туризмга ярдәм итү мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов